# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XXXIII СЕССИЯСЕ

**К А Р А Р № 187**

Мөслим авылы «29» мая 2024 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 31 июлендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Федераль законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 31 июлендәге 155 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 16 статьяның 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Муниципаль хезмәткә кергәндә әлеге Нигезләмә нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган белешмәләр (анкетадагы белешмәләрдән тыш) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерелергә мөмкин.»;

1.2. 16 статьяның 4 пунктындагы 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт турындагы федераль законнар нигезендә анкета;»;

1.3. 11 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән чорда ялган документлар һәм (яисә) аны бозган өчен муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрнең, тыюларның һәм таләпләрнең үтәлүен раслый торган, яисә документларның һәм (яисә) белешмәләрнең, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә тоткарлык ясый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәве турында таныклый торган белешмәләрне тапшырганда;»;

1.4. 10 статьяның 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле 13 пункт белән тулыландырырга:

«13) эш бирүчегә, үзгәртүе эш бирүче карары буенча булган белешмәләрдән тыш, анкетадагы мәгълүм үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетадагы белешмәләр).»;

1.5. 19 статьяның 1 пунктын - төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны рәсми рәвештә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы Башлыгы А.Р.Хужин